Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлегенең
Миңлебай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

28 ноябрь 2022 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2022 елның 24 ноябрендә 17 сәгать 00 минутта, 2022 елның 24 ноябрендә 18 сәгать 00 минутта узган гражданнарның этаплы җыен нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге "Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге Миңлебай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: Миңлебай авылындагы юлларны асфальтлау, техник күзәтчелек үткәрү?" соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 749 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 532 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 532 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлегенең Миңлебай авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге Миңлебай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 700 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару: Миңлебай авылындагы юлларны асфальтлау, техник күзәтчелек үткәрүгә ризамы?" турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Миңлебай авылы, Ш.Бикчурин урамы, 50 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Миңлебай авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Миңлебай авыл җирлеге башлыгы И.М. Рәхимов